РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2025_ №218-п

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь төзелеш министрлыгы боерыгы проекты буенча «Кадастр номеры 16:35:200116:613 булган җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 01-09-25437 номерлы «Иҗтимагый фикер алышу үткәрү турында» хаты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 39 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гавами тыңлаулар һәм иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 20 апрелендәге 209 номерлы карарына ярашлы рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

**1.** 1.Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (алга таба - проект) (кушымта).

**2.** Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

**3.** Проект буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 25 ноябрендә 15:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Яшьләр ур., 8 йорты адресы буенча урнашканШәмәрдән мәдәният йорты бинасында уздырырга.

**4.** Проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы,Лермонтов урамы, 2 йорт (эш көннәрендә-8.00 дән 16.30 га кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән гавами

тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты – 2025 елның 24 ноябре. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздырган вакытта язма рәвештә яисә телдән бирелергә мөмкин.

**5.** Ачык тыңлауларны, шәһәр төзелеше законнарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2023 елның 20 апрелендәге 209 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә уздырырга.

**6.** Гавами тыңлауларны оештыручыга:

– 2025 елның 05 ноябренә кадәр әлеге карарны Саба муниципаль районының рәсми сайтында ( http://pravo.tatarstan.ru) «Гавами тыңлаулар» бүлегендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга:http://pravo.tatarstan.ru;

– Саба муниципаль районының рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) халыкка гавами тыңлаулар үткәрелә башлау турында «Авыл җирлеге бинасы янында җиһазланган авыл җирлеге мәгълүмат стендларында һәм гавами тыңлаулар» бүлегендә хәбәр итәргә:

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында һәм аңа мәгълүмати материаллар, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының яисә җыелышларының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат күрсәтергә.

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка мәгълүмати материаллар исемлеген бирергә;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат урнаштырырга;

4) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенең яки экспозицияләренең урыны, ачылу датасы турында, мондый проектның экспозициясен яки экспозициясен үткәрү сроклары турында, күрсәтелгән экспозицияләргә яки экспозицияләргә керү мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат урнаштырырга;

5) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар кертү тәртибе, срогы һәм рәвеше турында мәгълүмат урнаштырырга;

– җирдән чиктәш файдаланучыларга гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итәргә;

– «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздыруны, тиешле мәгълүмат урнаштыру һәм билгеләнгән процедураларны, шулай ук гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләрен бастырып чыгару юлы белән тәэмин итәргә;

– 2025 елның 05 ноябреннән 25 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Лермонтов урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында һәм Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Яшьләр ур., 8 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачарга һәм уздырырга. Экспозицияне эш көннәрендә 8:00 дән 16:00 гә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү, проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән оештырылырга тиеш;

– гавами тыңлауларга әзерлекне, гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны гавами тыңлауларда мәҗбүри карау белән тәэмин итәргә,

– гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән сроклар нигезендә уздыруны тәэмин итәргә;

– гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм рәсмиләштерү;

– Гавами тыңлаулар йомгаклары буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтының "Гавами тыңлаулар" бүлегендә: http://saby.tatarstan.ru урнаштырырга.

**7.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**8.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Миңнеханов

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА,
АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-
КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА
ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№

**ПРОЕКТ**

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып, **боерам:**:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл Башкарма комитетына, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авыл җирлеге, Шәмәрдән авылы, Совет урамы, 2Б йорт адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:35:200116:613 булган, 69 кв м мәйданлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының “Шәмәрдән авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасындагы- «Коммуналь хезмәт күрсәтү» җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Территорияләрне үстерү департаментының Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.В. Ароновага) әлеге боерыкның юнәлешен Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны тәэмин итәргә

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Территорияләрне үстерү**
**Департаменты җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Шәмәрдән авыл җирлеге» МБ 2021 елның 12 августыннан №75 нче номерлы «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре»**




**Шәхси торак төзелеше зонасы (Ж1)**

Земельный участок: 16:35:200116:613

Информация Сервисы Объекты Части ЗУ Состав

| | |
|---|---|
| Вид объекта недвижимости | Земельный участок |
| Вид земельного участка | Землепользование |
| Дата присвоения | 14.10.2025 |
| Кадастровый номер | 16:35:200116:613 |
| Кадастровый квартал | 16:35:200116 |
| Адрес | Российская Федерация, Республика Татарстан, Сабинский муниципальный район, Шеморданское сельское поселение, с Шемордан, ул. Советская, д. 2Б<br>Свернуть |
| Площадь уточненная | 69 кв. м |
| Площадь декларированная | - |
| Площадь | - |
| Статус | Учтенный |
| Категория земель | Земли населенных пунктов |
| Вид разрешенного использования | Земельные участки (территории) общего пользования |
| Форма собственности | Муниципальная |
| Кадастровая стоимость | 11 067,85 руб. |
| Удельный показатель кадастровой стоимости | 160,4 руб./кв. м |

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Шәмәрдән авыл җирлеге» МБ Генераль планы**







**Территориялəрдəн файдалануның махсус шартлары булган торак зоналары**

су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклау зонасының өченче поясы;

**Шәхси торак төзелеше зонасы (Ж1)**

| **Рөхсәт ителгән файдалану төре** | | **Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең һәм реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Код** | **Атамасы** | **җир кишәрлегенең күләме, кв.м** | **катлар саны / төзелеш биеклеге** | **Төзелешнең максималь проценты** | **җир кишәрлеге чикләреннән минималь** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **чигенүләр, м** |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |
| 3.1 | Коммуналь хезмәт күрсәтү | н.у. | н.у. | н.у. | н.у. |